СОВЕТ НАРМОСКОГО ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422630 ,РТ, Лаишевский район,
село нармонка, ул.Молодежная, д.12а
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН НАРМОНКА АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422610 Лаеш районы,Нармонка
авылы
Яшьлэр ур., 12 а анчейорт
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

**2019 елның 18 ноябрендәге 173 номерлы**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге составына керүче Караишево торак пунктындагы гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге составына керүче Караишево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Караишево торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту
- Нармонка авыл җирлеге составына керүче Караишево торак пункты җирлеген су белән тәэмин итү системасын реконструкцияләү.

3. Әлеге карарны Нармонка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _______________Стерякова Л.Д.
(имза) (расшифровка)

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Нармонка авыл җирлеге Советы рәисе_________ Стерякова Л.Д.